Бүгенге санда:



Нурлатта штаб өйрәнүләре узды. 2 бит


1931 елның 9 июленнән бирле чыга

# Дуслык

Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Җомга 13 март 2015 ел

№ 18 (10547)


**14 мартка һава торышы:** аязучан болытлы һава, җил төньяк- көнбатыштан 3-4 м/с; температура көндез +1°С, төнлә -7°С

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

*Абзац-информ*

### МЕДАЛЬЛӘР ТАПШЫРЫЛА

Районда Җиңүнең 70 еллыгы медальләрен тапшыру дәвам итә. Чәршәмбе көнне шәһәрнең Ключи микрорайонында яшәүче 16 ветеранга бүләкләрне район башкарма комитеты җитәкчесе Әсхәт Габдуллин тантаналы шартларда тапшырды.

### ҮЛЕМ БЕЛӘН СӘҮДӘ ТЫЕЛА

16 марттан Татарстанда "Үлем белән кайда сәүдә итүләрен хәбәр ит!" Бөтенроссия акциясе старт ала. Акциядә һәм листовкалар таратуда волонтерларның, "Мөстәкыйль балалар" проекты әгъзаларының катнашуы планлаштырыла.

### БЕР МӘКТӘПКӘ – ИКЕ ДИПЛОМ

Альберт Терентьев исемендәге Идел буе экологик конференциясеннән шәһәрнең 3нче мәктәбеннән укытучы Татьяна Чибидина җитәкчелегендә катнашкан ике укучы да уңышка ирешеп кайтты. 11 сыйныф укучысы Азат Мусин "Гамәли табигатьне саклау эшчәнлеге" секциясендә чыгыш ясап, иң югары балл җыюга иреште һәм диплом белән бүләкләнде. Ә 8 сыйныф укучысы Яна Игнатованың "Гомуми экология" секциясендәге чыгышы "Тикшеренүнең эчтәлекле фәнни юнәлеше өчен" дипломына лаек булды.

### КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ

Коррупцион юнәлештәге хәбәрләрегезне кайнар линия телефоны аша җиткерә аласыз: 2-46-64 (Нурлат шәһәр прокуратурасы), 2-06-34 (район башлыгы каршындагы коррупциягә каршы тору комиссиясе).

### ЯРМИНКӘГӘ КИЛЕГЕЗ!

**Шимбә, 14 март көнне,** Гыйматдинов урамында иртәнге 6дан авыл хуҗалыгы ярминкәсе оештырыла. Бу көнне шәһәрлеләргә авыл хуҗалыгы продукциясе чамалы бәяләрдән зур ассортиментта тәкъдим ителәчәк. Рәхим итегез!

# Рөстәм Миннеханов "Адмирал"дагы янгынның сәбәбен тикшерүне шәхси контроленә алды




Татарстан Президенты Казанда янгын чыккан сәүдә үзәгендә күчмә экстрен киңәшмә үткәрде. Республика лидеры янгын чыгуның сәбәбен җентекле итеп тикшерүне, зыян күрүчеләргә медицина ярдәме күрсәтүне һәм "Адмирал" сәүдә үзәгендә эшчәнлек алып барган барлык эшмәкәрләрне шәһәрнең башка сәүдә үзәкләрендә сату итү өчен урыннар белән тәэмин итүне йөкләде. Президент күрсәтмәсе нигезендә, Казанда һәлакәт нәтиҗәсендә зыян күрүчеләргә ярдәм итү буенча оператив штаб төзелде.


*Бу хакта тулырак "Атна вакыйгалары"нда укый аласыз*


## Авыл хуҗалыгы алдынгылары хөрмәтләнә

БҮГЕН НУРЛАТТА АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ АЛДЫНГЫЛАРЫ СЛЕТЫ ҮТӘ.

**Слетта ел дәвамында басу-кырларда тырышып хезмәт куйган, терлекчелектә зур уңышларга ирешкән авыл хезмәтчәннәре, хуҗалык җитәкчеләре һәм белгечләре, гаилә фермалары, шәхси хуҗалыклар хөрмәтләнәчәк. Слетка районның барлык хуҗалыкларыннан 200 кеше чакырулы.**


*Теманың дәвамы – 3нче биттә.*


АКТУАЛЬ

# Ташулары белән яз килә

**Нурлат районында 7 авыл язгы су басу ихтималы булган зонага керә.**

Язгы чор башлану белән районда тормыш аерата көчле әзерлек стадиясенә керә, дияргә мөмкин. Шуңа да иң тәҗел бурычлар язгы ташу чорында кисәтү чаралары һәм бу вакытны аварияләрсез уздыруны оештыруга бәйле. Боларга су торбаларын, су җибәрү каналларын кардан, боздан һәм чүп-чардан чистарту да, автоюлларның торышына контрольлек итү дә керә.

– Киекле, Заречный, Кычытканлы, Якты Күл, Мамык, Тәрнәс, Якушкино – әлеге авылларда гидрологик постлар оештырылачак, – диде Нурлат гарнизоны начальнигы Илһам Курамшин. – Алар тәүлегенә ике, ә ситуация катлауланса, дүрт тапкыр су дәрәҗәсенең күтәрелү күрсәткечләрен районның бердәм диспетчерлык службасына җибәрәчәкләр, һәм бу мәгълүмат гомумиләштерелеп республиканың гадәттән тыш хәлләр комиссиясенә, МЧСка юллана. Язгы ташуны аварияләрсез уздыру гидротехник корылмаларны файдалануда куркынычсызлыкны тәэмин итүгә дә тыгыз бәйләнгән, алар районда 23әү. Районда барлыгы 215 су агу торбасы һәм 29 күпер бар, шуның берсе әлегә ремонтта. Алар чистартылган һәм кар суларын агызуга әзерләнгән. Юл службалары базаларында инерт материаллар запасы әзерләнгән: 40 тонна вак таш, 112 тоннадан артык ком бар. "Промочистка", кирәге чыкса, бу чорда эчә торган суны зарарсызландыру өчен 18 тонна төрле реагентлар һәм 35 тонна известь запасы булдырды. Язгы ташуны фаразлавы кыен. Метеорологлар яз өчен иң кулай һава торышы көндез плюслы, төнлә минуслы температура, диләр. Һәм әлегә бездә нәкъ шундый һава торышы күзәтелә дә.

– Кыш карлы булды, 10 мартка кар катламының калынлыгы кырларда 35 сантиметр тәшкил итә иде, – диде Чулпан метеостанциясе начальнигы Наталья Матвеева. – Хәзер температура режимының күтәрелүе күзәтелә. Әгәр дә җирнең туңы 1 метрдан артып китсә, кар тиз эрегән очракта су басуы ихтимал.

– Әлегә һава шартлары су басу ихтималы булган барлык объектларны һәм участокларны контрольдә тотарга, азык-төлек, медикаментлар, ягулык-майлау материаллары запаслары, йөзү чаралары, мотопомпалар, электр станцияләре булдырырга мөмкинлек бирә, – ди гарнизон начальнигы.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

# РАЙОН ТОРМЫШЫ

ӨЙРӘНҮЛӘР

## Нурлат саклануга әзер

**11 мартта Нурлат масштаблы команда-штаб өйрәнүләре урынына әверелде. Моның өчен районга хокукка каршы гамәлләр имитацияләү өчен Яр Чаллыдан омончылардан торган 10 төркем, җәмгысе 65 кеше килде. Өйрәнүләргә ТР эчке эшләр министры урынбасары Дамир Динниулов җитәкчелек итте.**

Асылда шәһәр бер көнгә төрле җинаятьчел каршылыкларның массакүләм басып алу объектына әверелде. Башта ук өйрәнүләр урыны итеп потенциаль куркыныч булган биш яшәешне тәэмин итү объекты сайланды, алар арасында элемтә, нефтебаза, подстанция, элеватор, геофизика бар иде. Әмма имитация төркеме моннан да зуррак мәйданны колачлады. Команда-штаб өйрәнүләренең асылына безнең районда ихтимал булган реаль ситуация салынган иде.

Иртәнге 9да гимназия бинасына билгесез хатын-кыз үтеп керергә маташа, соңрак ачыклаганча, аның шартлаткычы да була икән. Каравылчы аны үткәрми, һәм бу белем бирү учреждениесенә үтеп керүнең чикләнгәнлеген җиткерде. Биредә фойеда ук шартлау имитациясе гамәлгә ашырылды, барлык службалар да оператив эш итте, укучылар эвакуацияләнде. Өйрәнү гамәлләреннән соң, РУЭСка күчтеләр, бинага террорчылар үтеп керә алмады, әмма үзәк мәйданга шартлаткычлы машинаны бернинди каршылыксыз алып керә алдылар. Шартлы террорчыларның гамәлләре төрле планда иде. Алар шартлаткыч матдәләрне элеватор территориясенә куйдылар, бу исә уяу нурлатлыларның игътибарыннан читтә калмады, алар бу хакта кизү частенә хәбәр иттеләр. ОМВД һәм НРЭС биналарына керергә маташулары да уңышсыз булды, аннан алар РИТЭКны басып алырга омтылдылар, әмма биредә дә бу ниятләре барып чыкмады, шартлау булмый калды. Үзәктәге банкта да шартлаткычны үзвакытында сизеп алдылар. Тимер юл вокзалында шартлы җинаятьчеләр начальник кабинетына үтеп кереп, ут төртеп карадылар. Шулай да өйрәнүләрнең иң кызуы геофизикага эләкте, анда террорчылар алты кешене тоткынлыкка алдылар, акча таләп итә башладылар, берсен шартлы рәвештә үтерделәр. Нефтебазада шартлаткычлы машина тоткарланды.

Эчке эшләр бүлеге начальнигы Хафиз Нургатин билгеләп үткәнчә, бүлектә коралланган һәм аеруча куркыныч җинаятьчеләрне эзләү өчен личный составны җыю турында "Вулкан-4" һәм шәхси объектларны саклау буенча "Крепость" операцияләре игълан ителгән. Тулаем алганда, өйрәнүләр уңышлы үтте дияргә мөмкин. Моны ТР эчке эшләр министры урынбасары Дамир Динниулов та билгеләп үтте.

Дамир Равилевич район объектларының яхшы ныгытылганлыгын, бу мәсьәләгә җитәкчеләрнең нык игътибар бирүен билгеләп үтте һәм Нурлатта өйрәнүләр уңай бәягә лаек, дип нәтиҗә ясады.




**ДАМИР ДИННИУЛОВ:**
*– Тактик өйрәнүләр уңышлы узды, подразделениеләрнең оператив гамәлләргә әзерлекләре расланды. Нурлатта соңгы өйрәнүләр 5 ел элек үткәрелгән иде, аның белән чагыштырганда, быел әзерлек дәрәҗәсенең һәм профессиональ грамоталылыкның үсеше күзәтелә.*

Министр урынбасары эшлекле визиты азагында район башлыгы Равил Кузюров белән очрашты, анда җәмәгать куркынычсызлыгы мәсьәләләре турында сөйләшенде.

Валентина ВАФИНА

КӨН КАДАГЫНДА

## Бердәм эшләсәк кенә




СӨЙЛӘШҮ ТЕМАСЫ УЙЛАНДЫРЫРЛЫК ИДЕ

**10 мартта шәһәр Мәдәният сараенда Нурлат муниципаль районы территориясендә дини экстремизм һәм терроризмга каршы тору һәм профилактикалау чаралары торышы турында зур сөйләшү узды.**

Район башлыгы Равил Кузюров рәислегендә үткән сөйләшүгә хокук саклау органнары вәкилләре, имамнар, авыл җирлекләре башлыклары чакырулы иде. Очрашуда әлеге темага Нурлат шәһәре прокуроры Рамил Гарифуллин, ТР Президентының эчке сәясәт мәсьәләләре буенча Департаменты дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек итү Идарәсенең дәүләт-конфессияара мөнәсәбәтләр бүлеге Баш киңәшчесе Руслан Мәрданшин, ФСБ идарәсе хезмәткәре Ирек Незеев, Чистай оператив зонасының экстремизм һәм терроризм мәсьәләләре буенча бүлек начальнигы Фәрхәт Сафиуллин чыгыш ясадылар, сөйләшүдә ТР Дәүләт Советы депутаты Шамил Яһудин да катнашты.

– Районда әлеге мәсьәләдә тынычланырга һич ярамый, - диде шәһәр прокуроры Рамил Гарифуллин. - Узган ел гына да экстремизм һәм терроризм буенча 3 кешегә карата җинаять эше кузгатылды. Район мәчетләренең берсендә дә янгын, сак сигнализацияләре юк. Узган ел 23 авыл җирлегендә тикшерү эшләре алып бардык, нәтиҗәләрдән күренгәнчә, дини экстремизм мәсьәләсендә авыл җирлекләре башлыклары тиешенчә эшләп җиткерми. Моннан тыш, шәһәрдә төзелеп килүче мәдрәсәне оформить итү буенча да башкарасы эшләр күп.

Чистай оператив зонасының экстремизм һәм терроризм мәсьәләләре буенча бүлек начальнигы Фәрхәт Сафиуллин билгеләп узганча, иминлек үзебездән тора. Ул чит ил гражданнарын теркәү буенча Ютазы районын үрнәк итеп китерде. Ә безнең районда бу эш 2013 елдан гамәлдә инде. Һәр авыл җирлеге полиция һәм миграция бүлекләре белән өч яклы килешү нигезендә эшли. Мөхтәсиб Айрат хәзрәт Әюпов, Биккол авылы имамы Рафаэль Гәрәев һәм Киекле авыл җирлеге башлыгы Рәфис Ганиев әлеге мәсьәләдә үз тәҗрибәләре белән уртаклаштылар.

– Бу килешү нигезендә миграция бүлеге аша авылларга яшәү өчен килгән чит ил гражданнары турында бик тиз арада мәгълүмат алабыз, - ди Киекле авыл җирлеге башлыгы Рәфис Ганиев. – Ул гражданнарның шәхесен ачыклау өчен полиция участковыена мөрәҗәгать итәбез. Ай саен үз җирлегебездә гражданлык статусы булмаган кешеләр турында прокуратурага хисап тотабыз. Узган ел Киекле авылында ачылган полиция участогы хокук сакчыларына халык белән тыгыз элемтәдә торырга ярдәм итә. Һәр айның бер көнендә участковый белән берлектә хуҗасыз йортларга, ялгыз яшәүчеләргә рейд оештырабыз.

Чарада чыгыш ясаган район мөхтәсибе Айрат хәзрәт Әюпов та әлеге теманың актуальлеген билгеләп үтте.

– Агымдагы ел - авыр елларның берсе, - диде мөхтәсиб. – Бу - сайлаулар елы да, кризис чоры да. Бүген каралган мәсьәлә күп службаларны, шул исәптән безне дә борчый. Моннан 4 ел элек районда хәл куркынычрак иде. Эшләнгән эшләр бихисап. Әмма болары гына җитеп бетми, күрәсең. Алга таба бу өлкәдә эшне тагын да җанландырачакбыз.

Чарада катнашкан һәм чыгыш ясаган ТР мөфтие урынбасары Илдар хәзрәт Баязитов Нурлатта хакимият һәм хокук саклау, дини оешмаларның бердәм булып эшләвен билгеләп үтте. Ә олы сөйләшүгә нокта куяр алдыннан киләчәктә дә бергә һәм бердәм булып эшләргә дигән бурыч куелды.

Зилия ӘКСАНОВА

ХӘБӘРЛӘР

### МАХСУС ЧОРГА ӘЗЕР ТОРЫГЫЗ

**Чәршәмбе-пәнҗешәмбе көннәрендә районны махсус чорга күчерү буенча мобилизацияләнгән тренировка үтте.**

11 мартта район Советының зур залында район башлыгы урынбасары Флюра Ногманова рәислегендә мобилизация тренировкалары үткәргәндә кабул итү-эвакуация комиссиясенең утырышы узды, анда тренировкаларга кагылышлы мәсьәләләр каралды. "Бурычларның берсе булып гражданнар оборонасы буенча чараларны башкару мәсьәләсен эшләү тора", – диде Ф.Ногманова. Шунда ук эвакуация эшләре буенча җаваплылар үз службаларының әзерлекләре турында хисап җиткерделәр. "Гражданнар оборонасы буенча планлаштырылган чараларны әлегә шартлы рәвештә, документлар буенча башкарабыз, гражданнар оборонасы һәм кабул итү-эвакуация пунктлары службаларын эшкә җикмибез. Шуңа да районның барлык службалары һәм гражданнар оборонасы формированиеләре җитәкчеләренә планлаштырылган чараларны шартлы үтәүгә керешергә, өйрәнүләр үткәрергә, матди-техник чараларның торышын тикшерергә. Районның гражданнар оборонасы штабына телефон, факс, электрон почта, посыльныйлар ярдәмендә гражданнар оборонасы көчләре һәм чараларының үзара хезмәттәшлеген оештырырга", – дип йомгаклады сүзен Флюра Ногманова.

Сирень СӘМӘРХАНОВА

### МОГҖИЗАЛАР ИЛЕНӘ СӘЯХӘТ

**Һәр айның икенче сишәмбесендә үтүче мәдәният хезмәткәрләренең район семинары 10 мартта район мәдәният йортында мастер-класс формасында үтте.**

8 Март – Халыкара хатын-кызлар көненә багышлап "Могҗизалар тәгәрмәче" ("Колесо чудес") дип аталган чарага районның 55 мәдәни учреждениесе хезмәткәре һәм техник персоналы чакырулы иде. Программаның авторы, мәдәни үсеш үзәгенең административ-хуҗалык бүлеге мөдире Вячеслав Итрин семинарны сорауларга җавап формасында оештырган иде. Шунда ук мәдәни хезмәткәрләр коллегаларына бәйрәм сәламнәрен концерт программасы формасында юлладылар.

Зилия ӘКСАНОВА

### КИТАПХАНӘДӘ – "ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ" УКУЧЫЛАР

**Үзәк китапханәдә шул көннәрдә үзенчәлекле чара үтте.**

Китапханә каршындагы хокукый мәгълүмат үзәге Бөтенроссия сукырлар җәмгыятенең Нурлат җирле оешмасы белән хезмәттәшлек кысаларында күрү һәм ишетү сәләтләре бозылганнар өчен танып - белү чарасы уздырды. Китапханәчеләр "үзенчәлекле" укучыларын яңа акцияләр һәм проектлар белән таныштырдылар, аларда актив катнашырга чакырдылар.

Маргарита ЛИТТА

### ДЕПУТАТ КАБУЛ ИТӘ

**Сишәмбе, 17 март көнне**, шәһәр Мәдәният сараенда көндезге 10нан 12гә кадәр нурлатлыларны ТР Дәүләт Советы депутаты **Рәис СӨЛӘЙМАНОВ** кабул итәчәк.

# ТОРМЫШ.КӨНКҮРЕШ




АЛЕКСАНДР АНИКИННЫҢ ТЕХНИКАСЫ ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕР

## Хезмәтләре хөрмәткә лаек

**Бүген узачак авыл хуҗалыгы алдынгылары слетында катнашачак механизаторлар арасында "Нурлат сөте" җәмгыятенең Сәләнгеш бүлекчәсеннән Александр Аникин да бар.**

Александр Николаевич авыл хуҗалыгында 35 елга якын хезмәт куя инде, бүлекчәнең иң тырыш механизаторларыннан ул. Әнә, узган елда механизаторның хезмәт җитештерүчәнлеге 2800 шартлы эталон гектар тәшкил иткән. Моңа исә төгәллеге, җаваплы булуы белән ирешә тракторчы, ел әйләнәсе ике – МТЗ-80 һәм Т-215 тракторларында чиратлаштырып эшләргә өлгерә. Бу көннәрдә исә хуҗалыкның машина-трактор паркыннан кайтып та керми диярлек, чөнки биредә язгы чәчүгә техника ремонтының гөрләгән вакыты. Механизаторларның уртак тырышлыгы белән авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлап бетергәннәр инде, берничә трактор гына калган. Бүлекчәдә ремонт эшләренең барышы белән исә шул көннәрдә биредә узган район семинарында катнашучылар да таныша алдылар. Басуга чыгарга әзер булып, тигез рәтләргә тезеп куелган чәчү техникасын карадылар. Биредә үк район буенча язгы чәчүгә әзерлек мәсьәләләре каралды.

– Авыл хуҗалыгы машиналарын 25 мартка, тракторларны апрель башына ремонтлап бетерергә, - дигән бурыч куйды районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Ислам Сафиуллин. Идарә начальнигының хуҗалык белгечләрен ашыктыруы юкка түгел, чөнки быел язгы чәчү эшләре алдагы елларга караганда иртәрәк башланыр дип фаразлана.

Семинарда катнашкан район башлыгы Равил Кузюров әзерлек эшләренең җитди булырга тиешлеген билгеләп, хуҗалыкларда инде бүгеннән мобиль бригадалар оештыру өстендә эшләргә киңәш итте.

– Техника ватылу аркасында чәчү эшләрендә тоткарлыклар килеп тумасын өчен кирәк мобиль бригадалар. Алар теләсә кайсы вакытта басуга чыгып, техник ярдәм күрсәтә алырлык булсын, - диде ул.

Бу көнне семинарда исә терлекчелектә кышлату барышы да каралды. Семинарда катнашучылар бүлекчәнең сөтчелек фермаларын һәм бозаулату бүлекләрен карап үттеләр. "Нурлат сөте" җәмгыяте җитәкчесе Вәзир Сәгыйров әйтүенчә, бүгенге көндә биредә 873 баш мөгезле эре терлек асрала, шуларның 373е – савым сыер. Бүлекчәдә барлык күрсәткечләр дә узган елгы белән чагыштырганда арту ягында. Мәсәлән, узган елның шул чорында 1,7 тонна сөт сауган булсалар, бүгенге ул 3 тоннадан артыграк. Моңа терлекләрнең баш санын арттыру, көтүне яңарту, ашатуга индивидуаль якын килү һәм башка технологик таләпләргә җитди якын килеп ирешкәннәр. Район башлыгы да терлекчелектә иң беренче чиратта зоовет-таләпләрне истә тотып эшләргә чакырды. Шунда ук район буенча терлекчелекнең тулаем торышы каралды, алда торган бурычлар билгеләнде. Болар – көтүне яңарту, продуктлылыкны арттыру, язгы өзеклек чорына азык запасы булдыру һәм җәйләүләрне әзерләү.

Әнә шулай, авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре традицион бәйрәмнәрен көндәлек эшмәшәкатьләр, конкрет бурычлар белән каршы алалар.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

ҖИҢҮНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

## Тормышны яратып яшәүчеләрдән

**Бөек Ватан сугышы ветераны Вазыйх Кыямов үзенең 95 яшьлеге көнне, 10 мартта РФ Президенты Владимир Путин һәм Нурлат районы җитәкчелегеннән котлаулар кабул итте.**




БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ВЕТЕРАНЫ ВАЗЫЙХ КЫЯМОВКА БҮЛӘКНЕ ФЛЮРА НОГМАНОВА ТАПШЫРДЫ

Район башлыгы урынбасары Флюра Ногманова иң җылы теләкләрен теләп, ветеранга Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан чыгарылган юбилей медале тапшырды.

Вазыйх Романович I Белоруссия фронты составында сугыша. Әле 1940 елда ук армиягә алына, ә өенә 7 ел узганнан соң гына әйләнеп кайта.

– Мәскәүдән Берлинга кадәр җиттем, Җиңүдән соң ике ел Германиядә хезмәт иттем, – дип тыйнак кына хатирәләрен бүлешә Вазыйх Кыямов. Бүген ветеран ялгызы гына яши, социаль хезмәткәрләр ярдәменнән баш тарткан, хатыны вафат булганнан соң, тыйнак кына хуҗалыгын үзе алып бара, ә башка эшләрдә туганнары булыша. Әнә, юбилей көнне дә абыйсының улы Габделбари агасын котларга беренчеләрдән булып килеп җиткән. Бу гаиләдә өлкәннәргә хөрмәт һәм ихтирамлы мөнәсәбәт бала чактан ук тәрбияләнә.

Тантана хуҗасы - дөрес яшәү үрнәге, аның тормышы авыр хезмәткә бай, ә гомер барышында шатлык, матур кәеф өчен дә форсатлар җитәрлек,булган. Вазыйх Кыямовны кырыс сынаулар да сындырмаган. Һәм ветеран өчен озак гомер итү бер дә кыенга туры килми. Аның энергиясе ташып тора, тормышны яратуына һәм оптимистлыгына да сокланырлык.

**Маргарита ЛИТТА**

ӘЗЕРЛЕК

## Бүгеннән кайгырту кирәк

**Алда – язгы кыр эшләре, бакча мәшәкатьләре. Бу көннәрдә авыл хуҗалыгы предприятиеләре, шәхси бакчачылар орлык әзерләү белән мәшгуль. Әмма орлыклар белән бергә районга зарарлы карантинлы объектлар үтеп керү куркынычы да бар.**

– Моны булдырмас өчен кайтару белән орлыкларны Россельхознадзор идарәсенең Нурлат бүлекчәсенә алып килергә кирәк, ул Сәлимҗанов урамы, 16 адресы буенча урнашкан, - ди Россельхознадзор идарәсе дәүләт инспекторы Николай Ларионов. – Бу шулай ук орлыклар, дару үләннәре, җиләк-җимеш, яшелчә һәм ярган материаллар кайтару һәм сату белән шөгыльләнүче барлык оешмаларга, шәхси затларга, эшмәкәрләргә дә кагыла.

Николай Ларионов әйтүенчә, яз җитү белән карантинлы чүп үләне – амброзия проблемасы да баш калкыта. Нурлат районында амброзия буенча фитосанитар зона игълан ителгән. Анда 17 авыл җирлеге (нигездә Сөлчә, Чирмешән һәм Кондырча елгалары тирәсендәге торак пунктлар), 4 эре авыл хуҗалыгы предприятиесе керә. Шәһәрдә дә амброзияне кайбер мәктәп, балалар бакчалары территорияләрендә, Телестудия урамы, тимер юлчылар поселогында һәм башка урыннарда очратырга була. Ә бит амброзия нигездә балалар һәм өлкәннәргә куркыныч тудыра. Шуңа да дәүләт инспекторы инде бүгеннән әлеге карантинлы үләнне бетерү һәм таралуына юл куймау өчен чаралар планын эшләргә киңәш итә.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

КАЛЕНДАРЬДА ДАТА

## Бурычлары – контроль һәм профилактика

**12 мартта РФ Юстиция министрлыгының җәзаларны үтәтү хезмәткәрләре һөнәри бәйрәмнәрен билгеләп үттеләр.**

Нурлат муниципаль районында җәзаларны үтәтү системасы эшчәнлеген Россия ФСИның Татарстан Республикасы буенча җәзаларны үтәтү идарәсе федераль казна учреждениесенең Нурлат районы буенча филиалы алып бара. Филиалның төп бурычы – иректән мәхрүм итү белән бәйле булмаган җәзаларны үтәүгә контрольлек итү һәм филиалда исәптә торучы хөкем ителгәннәрнең кабат җинаятьләр кылуын һәм хокук бозуларын булдырмау өчен профилактика үткәрү.

Җәзаларны үтәтү инспекциясе филиалы аша 2014 ел дәвамында 415 хөкем ителүче узган. Хәзерге вакытта биредә 206 кеше исәптә тора.

Бүгенге көндә филиалда начальник, эчке служба майоры Айдар Сатдаров, өлкән инспекторлар Альберт Хәйруллин һәм Александр Николаев хезмәт куя.

**Валентина ВАФИНА**

## Сәламәт туклануга йөз тотып

**15 март – Бөтендөнья кулланучыларның хокукларын яклау көне.**

Бу дата календарьда моннан 21 ел элек барлыкка килгән. Быел ул "Кулланучылар хокукларын сәламәт туклануга туплыйк" шигаре астында уза.

–Хәзер начар туклануның сәламәтлеккә кире йогынтысы тәмәке тәэсиреннән дә күбрәк,–ди Роспотребнадзор территориаль органының әйдәп баручы белгеч-эксперты Алсу Әбделганиева.– Артык авырлыкка һәм симерүгә, канда шикәр һәм холестерин артуга китергән туклану күп үлемнәргә сәбәп була.

Районда кулланучылар хокукларын яклау көне уңаеннан 10-20 мартта үткәрелә торган чаралар кулланучыларның сәламәт туклануга хокукларын яклауга юнәлтеләчәк.

–Яшьләр арасында кулланучы грамоталылыгын күтәрүгә аерата игътибар биреләчәк,–ди Дәүләт алкоголь инспекциясенең Нурлат районындагы әйдәп баручы белгеч-эксперты Алия Гатина.–Белем бирү учреждениеләрендә семинарлар, лекцияләр, дәрес-практикумнар үткәрү планлаштырыла. Болардан тыш, базарларда һәм сәүдә комплексларында кулланучыларның сәламәт туклануга хокуклары һәм башка мәсьәләләр буенча консультацияләр биреп кизү тору оештырылачак.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА.**

*16 мартта "кайнар линия" телефоннары да эшләячәк: 2-17-71,2-08-83,2-19-45.*

# ТОРМЫШ.КӨНКҮРЕШ



Автор фотосы

АЛЕКСАНДР АНИКИННЫҢ ТЕХНИКАСЫ ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕР

## Хезмәтләре хөрмәткә лаек

**Бүген узачак авыл хуҗалыгы алдынгылары слетында катнашачак механизаторлар арасында “Нурлат сөте” җәмгыятенең Сәләнгеш бүлекчәсеннән Александр Аникин да бар.**

Александр Николаевич авыл хуҗалыгында 35 елга якын хезмәт куя инде, бүлекчәнең иң тырыш механизаторларыннан ул. Әнә, узган елда механизаторның хезмәт җитештерүчәнлеге 2800 шартлы эталон гектар тәшкил иткән. Моңа исә тегәллеге, җаваплы булуы белән ирешә тракторчы, ел әйләнәсе ике – МТЗ-80 һәм Т-215 тракторларында чиратлаштырып эшләргә өлгерә. Бу көннәрдә исә хуҗалыкның машина-трактор паркыннан кайтып та керми диярлек, чөнки биредә язгы чәчүгә техника ремонтының гөрләгән вакыты. Механизаторларның уртак тырышлыгы белән авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлап бетергәннәр инде, берничә трактор гына калган. Бүлекчәдә ремонт эшләренең барышы белән исә шул көннәрдә биредә узган район семинарында катнашучылар да таныша алдылар. Басуга чыгарга әзер булып, тигез рәтләргә тезеп куелган чәчү техникасын карадылар. Биредә үк район буенча язгы чәчүгә әзерлек мәсьәләләре каралды.

– Авыл хуҗалыгы машиналарын 25 мартка, тракторларны апрель башына ремонтлап бетерергә, - дигән бурыч куйды районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Ислам Сафиуллин. Идарә начальнигының хуҗалык белгечләрен ашыктыруы юкка түгел, чөнки быел язгы чәчү эшләре алдагы елларга караганда иртәрәк башланыр дип фаразлана.

Семинарда катнашкан район башлыгы Равил Кузюров әзерлек эшләренең җитди булырга тиешлеген билгеләп, хуҗалыкларда инде бүгеннән мобиль бригадалар оештыру өстендә эшләргә киңәш итте.

– Техника ватылу аркасында чәчү эшләрендә тоткарлыклар килеп тумасын өчен кирәк мобиль бригадалар. Алар теләсә кайсы вакытта басуга чыгып, техник ярдәм күрсәтә алырлык булсын, - диде ул.

Бу көнне семинарда исә терлекчелектә кышлату барышы да каралды. Семинарда катнашучылар бүлекчәнең сөтчелек фермаларын һәм бозаулату бүлекләрен карап үттеләр. “Нурлат сөте” җәмгыяте җитәкчесе Вәзир Сәгыйров әйтүенчә, бүгенге көндә биредә 873 баш мөгезле эре терлек асрала, шуларның 373е – савым сыер. Бүлекчәдә барлык күрсәткечләр дә узган елгы белән чагыштырганда арту ягында. Мәсәлән, узган елның шул чорында 1,7 тонна сөт сауган булсалар, бүгенге ул 3 тоннадан артыграк. Моңа терлекләрнең баш санын арттыру, көтүне яңарту, ашатуга индивидуаль якын килү һәм башка технологик таләпләргә җитди якын килеп ирешкәннәр. Район башлыгы да терлекчелектә иң беренче чиратта зоовет-таләпләрне истә тотып эшләргә чакырды. Шунда ук район буенча терлекчелекнең тулаем торышы каралды, алда торган бурычлар билгеләнде. Болар – көтүне яңарту, продуктлылыкны арттыру, язгы өзеклек чорына азык запасы булдыру һәм җәйләүләрне әзерләү.

Әнә шулай, авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре традицион бәйрәмнәрен көндәлек эшмәшәкатьләр, конкрет бурычлар белән каршы алалар.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

ӘЗЕРЛЕК

## Бүгеннән кайгырту кирәк

**Алда – язгы кыр эшләре, бакча мәшәкатьләре. Бу көннәрдә авыл хуҗалыгы предприятиеләре, шәхси бакчачылар орлык әзерләү белән мәшгуль. Әмма орлыклар белән бергә районга зарарлы карантинлы объектлар үтеп керү куркынычы да бар.**

– Моны булдырмас өчен кайтару белән орлыкларны Россельхознадзор идарәсенең Нурлат бүлекчәсенә алып килергә кирәк, ул Сәлимҗанов урамы, 16 адресы буенча урнашкан, - ди Россельхознадзор идарәсе дәүләт инспекторы Николай Ларионов. – Бу шулай ук орлыклар, дару үләннәре, җиләк-җимеш, яшелчә һәм ярган материаллар кайтару һәм сату белән шөгыльләнүче барлык оешмаларга, шәхси затларга, эшмәкәрләргә дә кагыла.

Николай Ларионов әйтүенчә, яз җитү белән карантинлы чүп үләне – амброзия проблемасы да баш калкыта. Нурлат районында амброзия буенча фитосанитар зона игълан ителгән. Анда 17 авыл җирлеге (нигездә Сөлчә, Чирмешән һәм Кондырча елгалары тирәсендәге торак пунктлар), 4 эре авыл хуҗалыгы предприятиесе керә. Шәһәрдә дә амброзияне кайбер мәктәп, балалар бакчалары территорияләрендә, Телестудия урамы, тимер юлчылар поселогында һәм башка урыннарда очратырга була. Ә бит амброзия нигездә балалар һәм өлкәннәргә куркыныч тудыра. Шуңа да дәүләт инспекторы инде бүгеннән әлеге карантинлы үләнне бетерү һәм таралуына юл куймау өчен чаралар планын эшләргә киңәш итә.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

КАЛЕНДАРЬДА ДАТА

## Бурычлары – контроль һәм профилактика

**12 мартта РФ Юстиция министрлыгының җәзаларны үтәтү хезмәткәрләре һөнәри бәйрәмнәрен билгеләп үттеләр.**

Нурлат муниципаль районында җәзаларны үтәтү системасы эшчәнлеген Россия ФСИның Татарстан Республикасы буенча җәзаларны үтәтү идарәсе федераль казна учреждениесенең Нурлат районы буенча филиалы алып бара. Филиалның төп бурычы – иректән мәхрүм итү белән бәйле булмаган җәзаларны үтәүгә контрольлек итү һәм филиалда исәптә торучы хөкем ителгәннәрнең кабат җинаятьләр кылуын һәм хокук бозуларын булдырмау өчен профилактика үткәрү.

Җәзаларны үтәтү инспекциясе филиалы аша 2014 ел дәвамында 415 хөкем ителүче узган. Хәзерге вакытта биредә 206 кеше исәптә тора.

Бүгенге көндә филиалда начальник, эчке служба майоры Айдар Сатдаров, өлкән инспекторлар Альберт Хәйруллин һәм Александр Николаев хезмәт куя.

**Валентина ВАФИНА**

ҖИҢҮНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

## Тормышны яратып яшәүчеләрдән

**Бөек Ватан сугышы ветераны Вазыйх Кыямов үзенең 95 яшьлеге көнне, 10 мартта РФ Президенты Владимир Путин һәм Нурлат районы җитәкчелегеннән котлаулар кабул итте.**

Район башлыгы урынбасары Флюра Ногманова иң җылы теләкләрен теләп, ветеранга Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан чыгарылган юбилей медале тапшырды.

Вазыйх Романович I Белоруссия фронты составында сугыша. Әле 1940 елда ук армиягә алына, ә өенә 7 ел узганнан соң гына әйләнеп кайта.

– Мәскәүдән Берлинга кадәр җиттем, Җиңүдән соң ике ел Германиядә хезмәт иттем, – дип тыйнак кына хатирәләрен бүлешә Вазыйх Кыямов. Бүген ветеран ялгызы гына яши, социаль хезмәткәрләр ярдәменнән баш тарткан, хатыны вафат булганнан соң, тыйнак кына хуҗалыгын үзе алып бара, ә башка эшләрдә туганнары булыша. Әнә, юбилей көнне дә абыйсының улы Габделбари агасын котларга беренчеләрдән булып килеп җиткән. Бу гаиләдә өлкәннәргә хөрмәт һәм ихтирамлы мөнәсәбәт бала чактан ук тәрбияләнә.



Автор фотосы

БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫ ВЕТЕРАНЫ ВАЗЫЙХ КЫЯМОВКА БҮЛӘКНЕ ФЛЮРА НОГМАНОВА ТАПШЫРДЫ

Тантана хуҗасы - дөрес яшәү үрнәге, аның тормышы авыр хезмәткә бай, ә гомер барышында шатлык, матур кәеф өчен дә форсатлар җитәрлек,булган. Вазыйх Кыямовны кырыс сынаулар да сындырмаган. Һәм ветеран өчен озак гомер итү бер дә кыенга туры килми. Аның энергиясе ташып тора, тормышны яратуына һәм оптимистлыгына да сокланырлык.

**Маргарита ЛИТТА**

## Сәламәт туклануга йөз тотып

**15 март – Бөтендөнья кулланучыларның хокукларын яклау көне.**

Бу дата календарьда моннан 21 ел элек барлыкка килгән. Быел ул “Кулланучылар хокукларын сәламәт туклануга туплыйк” шигаре астында уза.

–Хәзер начар туклануның сәламәтлеккә кире йогынтысы тәмәке тәэсиреннән дә күбрәк,–ди Роспотребнадзор территориаль органының әйдәп баручы белгеч-эксперты Алсу Әбделганиева.– Артык авырлыкка һәм симерүгә, канда шикәр һәм холестерин артуга китергән туклану күп үлемнәргә сәбәп була.

Районда кулланучылар хокукларын яклау көне уңаеннан 10-20 мартта үткәрелә торган чаралар кулланучыларның сәламәт туклануга хокукларын яклауга юнәлтеләчәк.

–Яшьләр арасында кулланучы грамоталылыгын күтәрүгә аерата игътибар биреләчәк,–ди Дәүләт алкоголь инспекциясенең Нурлат районындагы әйдәп баручы белгеч-эксперты Алия Гатина.–Белем бирү учреждениеләрендә семинарлар, лекцияләр, дәрес-практикумнар үткәрү планлаштырыла. Болардан тыш, базарларда һәм сәүдә комплексларында кулланучыларның сәламәт туклануга хокуклары һәм башка мәсьәләләр буенча консультацияләр биреп кизү тору оештырылачак.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА.**

*16 мартта “кайнар линия” телефоннары да эшләячәк: 2-17-71,2-08-83,2-19-45.*

# МАНЗАРА

ЯКТАШЛАР ОЧРАШУЫ

## Күңелләре әле дә туган җирдә

*– Әйдәгез, җыелып кайтып, авылдашларга бәйрәм ясыйк әле.*

Бикколда туып-үсеп, хәзер Нурлатта яшәүче Вәсилә Гәрәева күңелендә күптән йөрткән идеясен телефон аша якташларына җиткерде. Сәхнәгә чыгарлык иҗади күңелле якташларны эзләп аптырыйсы юк, барлый башлагач, авылның һәр йортында диярлек сәләтле талантлар үскәнлеге ачыкланды.

Ә авылдашлар шуны гына көткәннәрдер диярсең, кем күңеленнән яратып башкара торган җырларын исенә төшерде, кемдер кул эшләрен барлады, яңа шигырьләр язды, кайсылары хәтта сәхнә күренешләре сайлап, репетицияләр дә башлап җибәрде.

Очрашу авыл халкына да тансык булган икән. Әнә, яңа мәдәният йортының тамашачылар залы шыгрым тулы. Фойеда һәр килүчене кайнар чәй, коймак, татлы ризыклар көтә. Шунда ук кул эшләре күргәзмәсе. Мәләкәс районының Мулловка поселогында яшәүче Гөлкәй Гыйбадуллина крючок белән чигеп эшләнгән, үз куллары белән теккән курчакларын ике зур сумка төяп кайткан. Нурлаттан Гөлчәчәк Фәйзуллина, Гөлнара Сәфәргалиева, Алсинә Сөләймановaның кул эшләре дә күз явын алырлык. Ул да түгел, концерт программасы да башланып китте. Кайчандыр бала, үсмер чакларында авыл мәктәбе, клубы сәхнәләреннән төшмәгән якташлар хәзер дә иҗади тормышта кайнап яши. Әнә, Лаешта яшәүче Минегаян Киселева гомере буена җырдан аерылмаган, республикакүләм бәйгеләрдә җиңүләр яулаган. Бүгенге көндә күзләре яктылыкны тоймаса да, кулыннан гармунын куймаучы Алсу Кәримова, Себер якларында яшәп, хәзер Тольяттида төпләнгән Вахит Кәлимуллин, Нурлатта гомере буена балаларга белем биргән укытучы Нәкыя Гайфуллина, бораулаучы ярдәмчесе булып эшләүче Вәзир Вәлиәхмәтовның җырлы бүләкләрен дә алкышлап каршы алды авыл халкы. Озак еллар район мәгариф идарәсендә эшләп, лаеклы ялга чыккан Әлфия Гобәйдуллинаның гармун моңнары күпләрне яшьлекләренә алып кайтты. Баян партиясен алып барган Ринат Шаһиевка да алкышлар мулдан булды. Авылның хөрмәтле укытучылары Азат һәм Наҗия Вәлиәхмәтовларның уллары Рамил Нурлатта яшәп, эшләсә дә, төп нигезне таратмады, авыл тормышында кайный, бу көнне сәхнәдән җыр һәм көлкеле миниатюра күрсәтеп тә авылдашларны сөендерде. Яшьрәкләрдән Руфия Әһлиуллина, Гөлнара Мусина, Гүзәл Тәминдарова һәм Сиринә Шәрәпова сәхнәләштергән авыл кызының шәһәргә килү күренеше дә халыкның күңеленә хуш килде, Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче Розалия Идрисованың кызы Алсуның җыр, биюләрен дә яраттылар. Ә шәһәрлеләр авыл халкы өчен рухи бүләкләр белән бергә төрле номинацияләр буенча күчтәнәчләр дә әзерләгән. Бу көнне авыл хатын-кызлары дистәдән артык номинация буенча бүләкләнде, март аенда туган көннәрен, көмеш туйларын билгеләп үтүчеләр дә, читтән кайтып авылда оя корган авылдашлар да читтә калмады. Әнә, тумышы белән Бикколдан булган, бүгенге көндә районның ветераннар Советы рәисе Разыя Садретдинова тыл ветераннары, сугыш чоры балалары өчен бүләкләр әзерләп кайткан. Төп иганәчеләрдән булган "Нурлат сөте" җәмгыяте җитәкчесе Вәзир Сәгыйров та авыл халкына җылы теләкләрен җиткерде. Полковник, баш табиб урынбасары Мөнир Әхмәтшин һәм аның тормыш иптәше Гөлсирә ханым да авылдашларны котлап, бүләкләр тапшырды. Гөлсирә ханым авыл тарихын барлау, нәсел шәҗәрәсен төзү белән мәшгуль, бу көнне сәхнәдән авыл һәм аның кешеләренә багышланган шигырьләрен дә укыды.



СӘХНӘДӘ – КҮП ЕЛЛАР РАЙОН МӘГАРИФ ӨЛКӘСЕНДӘ ФИДАКАРЬ ХЕЗМӘТ КУЙГАН ӘЛФИЯ ГОБӘЙДУЛЛИНА

Хәтер яңартулар, концерт номерлары, бүләкләүләр белән үрелеп барган бәйрәм чарасы өч сәгатьтән артык дәвам итсә дә, халык китәргә ашыкмады. Шунда ук бәйрәмнең төп оештыручысы Вәсилә Гәрәевага рәхмәт әй... челәр дә күп булды. К... төрле якларга сибе... яшәүче бикколлылар... тагы да берләштер... ихлас чара һәм шәһ... леләрдән авыл хал... на онытылмаслык бү... булды бит.

Лилия МӨБАРӘКШ...

БӘЙРӘМ МИЗГЕЛЛӘРЕ

## Хөрмәт итәргә соңга калмыйк




СУГЫШТАН КАЙТУ КҮРЕНЕШЕ

**Югары Нурлат микрорайоны мәдәният йортында узган кичә Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан "Ул елларның даны мәңгелек" дип аталган чараны һәм 8 Март уңаеннан бәйрәмне берләштерде.**

Бу көнне тыл хезмәтчәннәре, сугыш чоры балаларын да хөрмәтләделәр. Барлыгы 27 кешегә Җиңүнең 70 еллыгына багышланган юбилей медальләре тапшырдылар. Шуларның икесе – Миннегали Әхмәтсафин, Шәрифулла Мөхәммәдьяров – Бөек Ватан сугышы ветераннары. Чарада катнашкан район башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасары Әлфия Галәветдинова, хатын-кызлар оешмасы җитәкчесе Фәридә Сәгыйрова тыл хезмәтчәннәренә район җитәкчелеге исеменнән рәхмәт сүзләре җиткерделәр. Әлеге җирлектә ул вакыйгаларның шаһитлары да кими бара. Агымдагы елда 90 яшьләрен тутырган Гөлмибәян Әһлиуллина һәм Ева Әхмәтсафинаның чордашлары бармак белән генә санарлык. Чарада катнашкан Гөлмибәян әби Әһлиуллина ул елларда 16 яшьлек үсмер кызларның окоплар казулары, хуҗалыкта эшләүләре, урман кисүләре турында сөйләде.

– 5нче сыйныфны тәмамлау белән минем өчен балачак тәгәлләнде инде, – ди Гөлмибәян әби ул елларны искә алып. – Авыл халкы җиңү көнен якынайту өчен көнне төнгә ялгап эшләде. Олы яшьтәге бабайлар белән хатын-кызлар һәм 9–10 яшьлек үсмер балалар иде алар. Авыл халкы ачлыктан үзе шешенеп үлсә дә, икмәкнең соңгы валчыгына кадәр сугыш кырына озатты. Ә без алабута онынан һәм туң бәрәңгедән пешергән ризык ашадык. Кырда калып туңган башак ашап үлүчеләр дә булды. Сыер асрый алганнарга җиңелрәк иде әле, тик еллар буе авыр хезмәткә җигелгән һәм үзләре дә ачлыктан интеккән сыерларның сөте җан башына бүлгәндә, тамчылап кына тия иде шул. Өстәвенә, авыл халкы үзенә дә булмаган сөт-маеннан хөкүмәткә салым да түләп барырга тиеш иде әле.

Бөек Ватан сугышына Югары Нурлаттан гына да 250 ир-егет киткән, шуларның 103е яу кырында ятып калган. Сугыш авылның 66 хатынын тол калдырган. Авылда сугыш аркасында 133 бала әтисез үскән. 12 бала әтиләре сугышка киткәндә, әниләренең карынында ук кала. Бу көнне сәхнә түрендә хөрмәтләнгән сугыш чоры балаларының уртаклашыр хатирәләре бихисап иде. Мәңгелеккә әтисез калдырган һәм гомер буе әти дип әйтергә тилмереп яшәргә мәҗбүр иткән көнне алар беркайчан да онытмаячаклар.

Район башкарма комитетының Мәдәни үсеш бүлеге һәм Югары Нурлат мәдәният йорты хезмәткәрләре "Ак калфак" хатын-кызлар иҗтимагый оешмасы белән бергә үткәргән чара тамашачыларны Сабан туена, кичке уенга, сугыш елларына һәм Җиңү көненә алып кайтты. Чарада агымдагы елда түгәрәк даталарын билгеләп үтүче юбилярлар да хөрмәтләнде. Мәдәният йорты директоры Гөлсинә Фәтхетдинова әйтүенчә, әлеге проектны авыл үзешчәннәре белән бергә әзерләгәннәр.

- Шөкер, микрорайоныбызда талантлы кешеләр җитәрлек, - ди мәдәният йорты директоры. – Сценарий авторыбыз да үзебезнеке, җырчы-биючеләребез дә бар. Бергә булып, бергә иҗат иткәндә, тамашачыларның күңелен күтәрү дә җиңел.

– Җиңүнең 70 еллыгына багышланган чаралар районның барлык авылларында да дәвам итәчәк, – ди "Ак калфак" татар хатын-кызларының иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Фәүзия Мөхәмматова. – Ул буын кешеләре санаулы гына калып бара. Шуңа да соңга калмыйча, игътибар күрсәтеп хөрмәтлисе иде аларны.

Зилия ӘКСАНОВА

КИЧӘГЕ ПОЧТАДАН

## РӘХӘТК... ТИЕНДЕ...

**Күптән түгел ачыл... җәмәгать мунчасына б... Яшьлек микрорайоны хал... сөенә-сөенә йөриб...**

Бу якларда яшәүчелә... үзәктәге мунча ерак, а... йөрү мәшәкатьләр ту... ра иде бит. Ә хәзер якы... гына булгач, җәяүләп тә... генә барып кайта алаб... Өстәвенә, мунча хезмәтлә... нең бәясе дә чамалы, пен... онерлар, халыкның ярдә... мохтаҗ катламы өчен т... ле ташламалар да б... Гаиләләләр өчен дә уңай... ир-атлар һәм хатын-кыз... заллары бер үк көнне эш... Әле тагын бер килгәндә... кистереп, мунчадан соң н... нар чәй эчеп алу. мөмкинл... дә бар, мунчага кунакка б... ган кебек киләбез. Эчке... да искиткеч матур, зәвы... итеп эшләнгән, кирәсе п... килеп тора. Ничәмә ел... буена ташландык яткан би... ның кыска гына вакыт эч... дә шундый зур үзгәреш... кичереп, уңайлыклы соци... объектка әверелүенә ни... сөенмисең ди? Бу эш ра... башлыгы Равил Кузюров и... циативасы белән башкар... ды, үтенечләрне аяк аст... салмыйча, халык өчен ты... шуы өчен зур рәхмәт аңа.

Рәзилә ЯКУПОВА, Яш... микрора...

# Осталар читтә дә сөрлекми

**Нурлат чаңгычылары күрше төбәкләрдәге ярышлардан призлар “чүпләвен” дәвам итә.**

Шул көннәрдә бер төркем чаңгычылар Кошки районының Антипкино авылындагы чаңгы узышларында катнашып кайттылар.

“Антипкинская лыжня” дип аталган ярышлар Самара өлкәсенең генә түгел, тирә-як төбәкләрнең дә иң гаярь чаңгычыларын җыйды. Нурлатлылар бу бәйгедән җәмгысе призлы унсигез урын алып, хуҗаларны да шаккатырды. Мисал өчен, Радик Ибраһимов, Александр Элекин, Рәсимә Кыямова, Илья Алексашкин, Алексей Михеев, Максим Панков үз дистанцияләрендә беренче килделәр. Моннан тыш, нурлатлылар исәбендә алты II һәм җиде III урын бар. “Шунысы сөенечле, барган саен хуҗалар тарафыннан үзебез адреска шактый комплиментлар алып кайтабыз. Кошки районы башлыгы Виктор Титов үзе дә көне буе спортчылар янында булды. Бу ярышларның Антипкино егете, Россиянең спорт мастеры, бүгенге көндә үзебезнең “Нурлатнефть” спортчысы Александр Элекинның инициативасы белән оештырылуын да билгеләп үтү кирәктер,” – дип ярышлардан алган тәэсирләрен уртаклаша “Антипкинская лыжня” җиңүчесе, СССР спорт мастеры Радик Ибраһимов.

Самара өлкәсенең Чаллы Башы районы Романовка поселогында әлеге төбәкнең Советлар Союзы Геройлары хөрмәтенә уздырылган ярышлардан да нурлатлылар уңышка ирешеп кайттылар. Мәсәлән, Виталий Герасимов, Виталий Кашкаров, Денис Панков, Евгений Кашкаров, Петр Казаков I урыннар алуга ирештеләр. Максим Панков II урын алды. Богдашкино чаңгычыларының тренерлары, шулай ук гамәлдәге спортчы Иван Белов әйтүенчә, Кошки авылында алар күңелле генә сюрпризга да тап булганнар икән. “Кошки үзәгендә чаңгычыларга багышланган бик зәвыклы, саллы гына плакат бар. Әнә шунда алгы планда минем укучым, Богдашкино кызы Регина Ефимова сурәтләнгән. Яшермим, бу хәлгә укучыларым да, үзем дә бик горурландык”, – ди Иван Белов. Заманында үзебездә дә, шул ук күрше төбәкләрдә дә һәр көндәшен “дер калтыратып” торган Регина бүген Казанда медколледжда белем ала, спорт белән шөгыльләнүен дә ташламаган икән.

Чирмешән районының Сосновка авылында “Три сосны” чаңгы узышларында да нурлатлыларның уникенче тапкыр катнашуы инде. Бу юлы аннан Кристина Белова, Анна Ефимова, Петр Казаков, Илья Айкин, Аркадий Романов җиңүче исемнәре яулап кайттылар. Моннан тыш, Иван һәм Дмитрий Беловлар, Валерий Трофимов – II, Анатолий Елаков, Максим Сандимиров, Виталий Кашкаров һәм Зарина Митрофанова үз дистанцияләрендә өченче килделәр.



АЙДАР ҖӘЕН САМАРАДА ЧАҢГЫ-РОЛЛЕРЛАРДА ШӨГЫЛЬЛӘНДЕ

# Айдар җәен дә җаен таба

**Күптән түгел Биккол егете, шәһәрнең 1нче мәктәбе укучысы, районның танылган яшь чаңгычысы Айдар Әндаров республикакүләм зур уңышка ирешеп кайтты.**

Март башында Зәй шәһәрендә СССРның атказанган спорт мастеры Василий Бекасов истәлегенә Татарстан чемпионатының III туры ярышлары үтте, һәм Айдар анда республиканың иң көчле чаңгычылары катнашкан 30 километрлы дистанциядә III урын алуга иреште. Яшь спортчының әтисе һәм тренеры Илһам Әндаров әйтүенчә, бу ярышларга алар әлләни зур өметләр багламыйча, үз көчләрен осталар арасында сынап карау максаты белән генә барган булганнар икән. “Беренче унлыкка эләгә алсак, бик шәп булачак, дип барган идек. Айдарның республикадагы мәртәбәле ярышларда катнашкалаганы бар иде инде, ә менә мондый саллы уңышка беренче ирешүе әле”, – дип тәэсирләрен уртаклашты Илһам Вазыйхович. Әлбәттә, Айдарның ярышларга ел әйләнәсе әзерләнүе дә зур йогынты ясагандыр монда. Ул җәй буе Самарада тренировкаларда булды, шул арада чаңгы-роллерлар буенча Самара өлкәсе ярышларында катнашырга да өлгергән. Мәсәлән, чаңгы-роллер спорты буенча Самара өлкәсе Кубогы турларында классика стилендә 10 чакрымлы дистанциядә җиңүгә ирешкән, шундый дистанциядә ирекле стильдә III, 5 километрлы дистанциядә II урыннар алган, шул рәвешле гомуми нәтиҗәләр буенча Самара өлкәсе Кубогын яулап кайтты ул. Быелгы кышкы сезонда да унбишләп ярышта катнашырга өлгергән ул. Әлеге бәйгеләрдә яулаган призлы урыннарын санау озакка китәр иде, әлбәттә. Шулай да иң саллы җиңүләрен телгә алу кирәктер. Мәсәлән, Кошки районының комплекслы спартакиадасында Айдар 20 яшькә кадәрге спортчылар арасында I урын алуга ирешә, шул районның башлыгы Виктор Титов призларына узышларда да җиңүче исеме яулап кайтты. Димитровград шәһәре Кубогының III этабында 10 чакрымлы дистанцияне өченче булып килде. Самара өлкәсе спартакиадасында да шундый ук дистанциядә өченче урын алды. Гомумән, Айдар соңгы араларда озын дистанцияләргә өстенлек бирә башлаган.

– Бүген Казан марафонына әзерләнәм, ул башкала мэриясе призларына уздырылачак, аннан Бөгелмәдәге марафонда катнашырга да исәп бар, – дип планнарын уртаклаша Айдар.

– Гомумән, атна саен ярышларда катнашырга туры килә. Рәхмәт, 1нче мәктәп җитәкчелеге, укытучылар хәлгә керә, ярышларга китәргә туры килгәндә дә беркайчан каршы төшмиләр. Калган дәресләрне куып тотарга да укытучылар бик теләп ярдәм итә, – ди Илһам Әндаров.

# Әлмәт күршеләрен ярышка җыйды

**Яңа Әлмәттә әлеге кустка кергән авыллар укучылары арасында традицион Спартакиада быел Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышлап һәм “Яшьләр наркотикларга каршы!” дигән шигарь астында узды.**

Бу Спартакиада өченче тапкыр уздырыла инде һәм ул быел да авыл укучылары өчен Сәламәтлек көне буларак үтте. Бу көнне укучылар тимераякта, чаңгыда узышу, армрестлинг, мылтыктан ату һәм милли көрәш кебек төрләрдә үз көчләрен сынадылар.

– Бу Спартакиада безнең кусттагы мәктәпләр укучылары өчен елның иң зур спорт чарасы булып тора, – дип саный Яңа Әлмәт мәктәбе директоры Зөлфирә Хамматова. – Хәзер авыл халкы да көтеп ала ярышларны.



КУНАКЛАРНЫ ИҢ ЭЛЕК ИМПРОВИЗАЦИЯЛӘНГӘН СОЛДАТ “ПРИВАЛЫ” КАРШЫ АЛДЫ

Шул рәвешле, Спартакиаданың быелгысында Әлмәт, Әмзә, Кычытканлы һәм Колбай Морасадан 50дән артык 4-9нчы сыйныф укучылары ярышты. “Район үзәгеннән шактый ерак урнашкан бу авыллар Нурлаттагы ярышларда еш катнаша алмый. Бу спартакиада да асылда әнә шул җитешсезлекне бераз булса да томалар өчен оештырыла. Нәтиҗәләрдән күренгәнчә, укучыларның әзерлеге шактый югары икәнлеге аңлашыла”, – ди район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җитәкчесе Әнәс Нәбиуллин. Хәер, бу яктагы мәктәпләрдә спортка җитди карыйлар анысы. Мисал өчен, шул ук Яңа Әлмәт мәктәбендә көрәш секциясе эшли. Инвентарьларыбыз да зарланырлык түгел, дип мәктәпнең физкультура укытучысы Рәис Хамматов. Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, мәгариф идарәсе ярдәмнәре белән кайтарылган чаңгы-тимераяклардан рәхәтләнеп файдаланалар. Авыл мәктәбе укучысы, гадәттә, универсаль була бит, шуңа бу Спартакиадада да алар мөмкин кадәр күбрәк спорт төрендә катнашырга ашкындылар. Тырышлыкларының әҗере дә мул булды: һәр төр буенча җиңүчеләр һәм призерлар грамота-медальләрдән тыш, Иске Әлмәт авыл җирлеге башкарма комитеты, яшьләр эшләре һәм спорт бүлегеннән бүләкләр дә алдылар. Ә Спартакиаданың төп Кубогын хуҗалар – Яңа Әлмәт мәктәбе командасы яулады.

## СПАРТАКИАДАДА

**Бу көннәрдә нефтьчеләрнең һәм республика укучыларының спартакиадалары дәвам итә.**

Шул көннәрдә Әлмәт шәһәрендә республика нефтьчеләренең XXVIII спартакиадасы кысаларында чаңгы ярышлары үтте. Анда “Татнефть” җәмгыятенең төрле подразделениеләре составында Нурлат спортчылары да матур нәтиҗәләр күрсәтеп кайттылар. Мисал өчен, “Нурлатнефть” НГДУсы чаңгычысы, Россия спорт мастеры Александр Элекин I урын яулап кайтты. “Нурлатнефть” идарәсенең тагы бер спортчысы Эдуард Жирнов дөнья чемпионы Владимир Назаровка бераз гына оттырып, икенче килде. Гомуми нәтиҗәләр буенча, “Нурлатнефть” командасының икенче урынга чыгуы да мактауга лаек. Моннан тыш, “Татнефтедор” җыелма командасы өчен йөгергән Нурлат автоюллар идарасе хезмәткәре Радик Ибраһимов үз дистанциясендә II урын алды. “Татнефть-Энергосервис” җәмгыятеннән Радик Сираҗетдинов җиңүче исемен яулап кайтты.

**СӘХИФӘНЕ ИЛНАЗ МӨБАРӘКШИН ӘЗЕРЛӘДЕ. АВТОР ФОТОЛАРЫ.**

# КОТЛАУЛАР. БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

## КОТЛЫЙБЫЗ!

**Киекле** авылында яшәүче **Гөлшат Хатыйп кызы Мөхәммәтованы** 50 яшьлек юбилее белән котлыйбыз. Кадерле сеңлебезгә ныклы сәламәтлек, гаилә бәхете, балалар шатлыгы, оныклар сөенече телибез.

Туган көндә матур теләк
Булсын әле үзеңә:
Күктән кояш балкып торсын
Нурлар сибеп йөзеңә.
Гөлшат! Синең юлларыңа
Бәхетләр яуса иде,
Безнең өчен һәрчак шулай
Яшь булып калсаң иде.

**Сине яратып апаларың Флюра, Әлфия, җизнәләрең Илгизәр һәм Әнәс. Безнең бу теләкләребезгә газиз әниебез дә кушыла.**

## КҮЧЕМСЕЗ МИЛЕК

*2 бүлмәле фатир, Нурлатта йорт, Егоркинода участок. Т.: 8-987-220-69-33, 8-927-422-34-44. 16-56-1.2004-588.1 м/х.
*Йорт. Т. 8-919-684-40-03.
*Дала Мамыгында йорт. Т. 8-965-610-28-57.
*Төньяк – Көнчыгыш мкр.да йорт. Т. 8-927-442-65-26.
*Сәлимҗанов ур., 9да 2 бүлмәле фатир. Т. 8-927-670-76-77.
*4 фатирлы коттеджда 3 бүлмәле фатир. Т. 89274744616.
*2 бүлмәле фатир, Ленинград ур., 9. Т. 8-917-894-52-56.
*Яңа йорт, эчке эшләре эшләнмәгән, Рябиновая ур. Т. 8-927-406-17-05.
*Ленинград ур.да 2 бүлмәле фатир. Т. 8-927-673-95-44.
*Нурлат шәһәре, Гыйматдинов ур., 117б адресы буенча җитештерү базасы. 7818 кв.м. мәйданлы җир участогы. Территориядә 753 кв.м. мәйданлы җылытыла торган склад урнашкан. Тимер юл кергән. Т. 8-937-002-72-72.
*1 бүлмәле фатир. Т.8-917-876-98-15
*2 бүлмәле фатир, Кариев ур. Т. 8-917-289-35-18.
*1 бүлмәле фатир,Дружба ур.,64, 2 кат. Т. 8-927-400-87-95.
*«Калейдоскоп» кибете, азык-төлек базарында. Т. 8-927-049-26-51.
*Вишневая Полянада дача өчен җир участогы белән иске йорт сатыла. Т. 8-965-412-53-02 (Галя).
*Йорт, т/ю. Т. 8-927-033-76-75, 2-21-99.
*Йорт, участок, газ, су, электр үткәрелгән, тоташтырылмаган. Т. 8-927-248-38-03.
*1 бүлмәле малосемейка. Т. 8-927-498-05-49.
*Йорт, Югары Нурлатта. Т. 8-965-582-11-72.
*2 бүлмәле фатир (евроремонт, үзәк). Т. 8-927-418-04-11.
*Шәһәр эчендә сүтеп алу өчен йорт, Гагарин ур., 2. Т. 8-937-659-44-94.
*Тимерҗанов ур.да 1 бүлмәле фатир. Т. 8-927-444-00-94.
*2 бүлмәле фатирлар: Гагарин ур., 2, индивидуаль җылытыла, ремонт, 1000000 сум; Гыйматдинов ур., 56, ремонт, 1300000 сум; йортлар: Тукай ур.да, 180 кв.м, 3500000 сум; Әхмәтов ур.да, 110 кв.м, 2100000 сум; 1 бүлмәле фатирлар, Завод тыкрыгы, 630000 сум; төзелеп бетмәгән йортлар: Дальняя ур., 1, Кыямов ур., 21. Т. 8-937-600-47-73 (Алсу).
*2 бүлмәле фатир, Сәлимҗанов ур.да, индивидуаль җылытыла, ремонтланган, җиһазлы. Йорт янындагы гаражы аерым сатыла. Т.: 8-917-884-63-05 (Әнвәр), 8-937-600-47-73 (Алсу).

## АВТОТРАНСПОРТ

*«Шевроле Спарк», 2009 елгы, 240 мең. Т. 8-927-424-47-31.
*«Дэу Нексия», 2007 елгы, 16-кл., яхшы. Т. 8-927-044-72-78.
*«Шевроле Нива», 2009 елгы, карасу-яшел «металлик». Т. 8-927-480-09-17.
*"KIA SIP", 2012 елгы. Т. 8-937-288-69-17.
*«ВАЗ-21213» (пикап), 2002 елгы. Т. 8-927-041-84-33.
*«Hyndai Getz», 2005 елгы. Т. 8-927-031-24-59.
*«ЗиЛ» (бычок), «ВАЗ-2105». Т. 8-927-440-31-55.
*«ВАЗ-2105», 2006 елгы, «ВАЗ-2114», 2006 елгы. Т. 8-937-293-32-10.
*«Рено Логан», 2013 елгы. Т. 8-937-280-66-69.
*МТЗ-80, МТЗ-82, 2007 елгы, чапкыч, КУН-10, бәрәңге утырткыч, казыгыч, пресс-рулон. Т. 8-919-632-55-99.
*«ВАЗ-2110», 1997 елгы, газ җайланмасы. Т. 8-927-246-85-25.

## БАШКАЛАР

*ПГС, елга комы, ком. Т. 8-927-247-27-37.
*Болын печәне, арпа, кукуруз, катнаш азык. Т.: 8-937-52-10-221, 3-52-39.
*Кәҗә сөте. Т. 8-937-293-36-19.
*Ком, ПГС, елга ташы, вак таш, кирпеч. Т. 8-927-401-51-91.
*ШИКӘР КОМЫ-2400, ОН-970, «Юмарт» кибете. Т. 8-927-445-68-55.

*Йомырка сала торган тавыклар. Китерәбез. Т. 8-937-617-05-16.
*ПГС, ком, төрле диаметрдагы кое боҗралары. Т. 8-937-286-20-82.
*Бозау, 2 айлык. Т. 8-927-413-42-04.
*Сыер ите, иткә яки нәселгә тәкә. Т. 8-927-245-32-03, 4-63-04(өй).
*Печән, салам, күп сөт һәм ит бирә торган токымлы бозаулар, бодай, ярдырылган бөртек, арпа, коры жом, кыйммәт түгел. Китереп бирү – түләүсез. Т.: 8-937-343-80-22, 8-909-345-99-77.
*Арпа,бодай. Т. 8-937-776-33-35.
*Яшь тавыклар. Т. 8-927-483-06-10, 8-917-293-27-47.
*Костер, люцерна орлыгы. Т. 8-927-470-39-02.
*Сыерчык оялары. Т. 8-937-570-50-55.
*Нарат,юкә такталары. Киров урманы. Т. 8-937-003-84-85.
*ПГС Т. 8-917-248-21-66, 8-927-675-54-96.
*Ком, ПГС, елга ташы, вак таш, кирпеч. Т. 8-927-247-94-76
*Ком, ПГС, елга ташы, вак таш. Т. 8-927-244-11-33.
*Таккычлар (Саранск, Курган). Т. 8-927-736-59-42
*Мунчага тимер мич Т. 8-917-872-36-16.
*Яшь тавыклар. Т.: 8-927-422-92-58, 4-35-11.
*Бәрәңге. Т. 8-937-291-43-87.
*Утын. Т. 8-937-003-27-27.
*Утын Т. 8-937-617-11-21.
*Льноватин (рулонлы чүбек). Т. 8-927-242-24-96.
*Ульян кәрәзе, 420 сум/кг. Т. 8-927-751-61-46.
*Һава чистарткыч, яңа. Т. 8-927-670-20-09.

**КАМЫШЛЫ ИНКУБАТОРЫ**
**тәүлеклек бройлерларга заявкалар кабул итә.**
**8-937-620-80-30 (Румия), 4-35-47 (өй).**

## ТӨРЛЕСЕННӘН

***Йомшак җиһаз тарттыру, ремонтлау. Т. 8-937-570-60-21.**
***Йөк күчерү, «ГАЗель». Т. 8-937-570-60-21.**
*Электрик хезмәтләре. Т. 8-987-418-35-00.
* Суыткычлар ремонтлыйбыз. Т.: 2-71-69, 8-937-610-58-78.
*Кер юу машиналарын ремонтлау. Т.: 8-927-468-16-31, 8-917-926-34-78.
*Суыткычлар ремонтлау. Т. 8-927-419-56-48.
*Электромонтаж эшләре. Т. 8-929-728-93-36.
*Керамзит, керамблоклар. Китереп бирү. Т. 8-927-72-47-85-89.
*Тарттырылма түшәмнәр. Т. 8-927-413-37-58, Иван.
*Тарттырылма түшәмнәр. Т. 8-927-036-53-65.
*Электрик хезмәтләре. Т. 8-937-761-470-15.
*Жалюзиның барлык төрләре, тиз. Т. 8-927-672-01-17.
*Компьютерлар, ноутбуклар көйләү, WI-FI, Интернет. Т. 8-937-005-14-51.
*Такси: Нурлат-Самара, өйдән. Т. 8-927-673-79-46
*«ГАЗель», йөк таксие. Т. 8-927-486-10-22.
*Отделка эшләре. Т. 8-937-620-00-60.
*Йөк күчерү, «ГАЗель», 4 м, 15 куб. Т. 8-927-247-12-61.
*Компьютерга ярдәм. Т. 8-909-308-22-56.

## БИРЕП ТОРЫЛА

*Тәүлекләп яки сәгатьләп фатир, командировкадагыларга Т. 8-927-456-05-69.
*Тәүлекләп фатир. Т. 8-927-448-33-48.
*Казанда фатир, озак вакытка. «Кәҗә бистәсе» метросы. Т. 8-927-241-60-83.
*Тәүлекләп фатир. Т. 8-927-406-11-06.
*Үзәктә бина, 6 кв.м. Т. 8-927-403-91-39.
*Арендага чәчтараш урыннары. Т. 8-937-287-68-88.
*1 бүлмәле фатир Т. 8-937-593-98-12.
*Арендага Кошки үзәгендә бина (70 кв.м). Т. 8-927-208-17-61.
*9нчы мәктәп янында 2 бүлмәле фатир. Т. 8-927-443-66-84.
*Гараж, Линейная ур. Т. 8-927-418-04-11.
*2 бүлмәле фатир. Т. 8-987-273-61-11.

## КИРӘК

*Медик белемле массажчы. Т.: 2-43-03, 2-43-04.
*Чәчтараш, 60%. Т. 8-937-287-68-88.
*«Спецэнергомонтаж»га эш тәҗрибәле бухгалтер. Адрес: Завод тыкрыгы, 1а (ЖБИ). Т.: 2-60-75, 2-50-90.
*Бина. Т. 8-960-041-96-86.
*«Уютный дом» ИКсына слесарьлар, эретеп ябыштыручылар. Хезмәт хакы 15000. Соцпакет. Т. 2-69-09.

## САТЫП АЛАМ

*Алгы приводлы «ВАЗ»лар, чит ил машиналары. Кыйммәткә. Т. 8-927-456-00-07.
*КЫЙММӘТКӘ АВТО. Т. 8-937-588-36-46.
*Мөгезле эре терлек, эре терлек тиреләре. Кыйммәткә. Т. 8-927-412-29-99.
*Каз-үрдәк йоны, иске мендәрләр, түшәкләр (тавык йонынnан тәкъдим итмәскә). Т. 8-987-062-55-26.
***Тимер калдыклары, кыйммәткә. Демонтаж. Үзебез алып китәбез Т. 8-927-422-26-66.**

## ЮГАЛТУЛАР

*16.06.2005 елда 99нчы ҺЛ тарафыннан Илмир Ирек улы Сатдаров исеменә бирелгән АО 528209 тракторчы-машинист таныклыгын югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.
*2010 елда "Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Андреевка урта гомуми белем бирү мәктәбе" тарафыннан Надежда Сергеевна Логинова исеменә бирелгән 16БВ 0033528 төп гомуми белем турындагы аттестатны югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.
*Вазыйх Котдус улы Габдуллин исеменә документлар белән кара барсетканы кайтарып бирүегезне сорыйм. Буш итмәм. Т.: 8-919-630-50-38, 8-927-481-74-26.
*Александр Васильевич Микушкин исеменә бирелгән АВ №221392 тракторчы таныклыгын югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.

## ЯРДӘМ ИТЕГЕЗ

*7 мартта Кочовлар гаиләсендә фаҗига чыкты – йортлары янды. Гаилә бер әйберсез калды. Битараф булмаган кешеләрнең ярдәм итүен үтенәбез.Т. 8-927-241-17-81.

**КОЕЛАР БОРАУЛАУ**
**РАЙОН БУЕНЧА КОЕ БОЖРАЛАРЫН КИТЕРЕП БИРҮ – ТҮЛӘҮСЕЗ.**
**Т. 8-9274-233-978.**

# УТИЛИЗАЦИЯ ПНГ В ОАО "ТАТНЕФТЬ"

**ОАО "Татнефть" продолжает развивать комплексную программу по утилизации попутного нефтяного газа (ПНГ).**

Для повышения эффективности утилизации ПНГ в Компании успешно реализованы различные проекты. Так, на установках предварительного сброса воды при подготовке нефти применяются печи нагрева нефти для доведения ее до товарных кондиций.

На объектах Компании, откуда транспортировка ПНГ затруднена, для выработки электроэнергии из ПНГ внедряются газопоршневые электростанции и микротурбинные энергоустановки, работающие на ПНГ. Благодаря высокой степени автоматизации энергосистема на базе микротурбин может функционировать без постоянного присутствия обслуживающего персонала. Мониторинг работы турбин осуществляется посредством микропроцессорной системы автоматического управления и имеет возможность использования "удаленного доступа". Данная программа позволяет контролировать параметры работы каждой турбины, при необходимости изменяя вырабатываемую мощность и производя диагностику. Электростанции, работающие на ПНГ, функционируют в нефтегазодобывающих управлениях "Ямашнефть", "Елховнефть" и "Бавлынефть".

Также в "Татнефти" ведутся строительство новых и реконструкция существующих газосборных сетей. Построены газосборные системы для сбора попутного нефтяного газа с объектов НГДУ "Альметьевнефть", НГДУ "Азнакаевскнефть" и НГДУ "Бавлынефть".

Дополнительные газопроводы построены для перекачки дополнительных объемов сероводородсодержащего газа на Кичуйской и Акташской установках подготовки высокосернистой нефти, а также для снижения давления на пунктах сепарации газа НГДУ "Елховнефть".

Для расширения мощностей по очистке газа Компания модернизирует и расширяет установки очистки попутного нефтяного газа от сероводорода управления "Татнефтегазпереработка". В 2015 году завершится реализация проекта реконструкции Миннибаевской установки сероочистки (УСО), направленного на повышение производительности установки.

По итогам 2014 года уровень эффективного использования попутного нефтяного газа Компании составил 95,17 процента.

Реализация запланированных мероприятий позволит поддерживать целевой показатель эффективного использования попутного нефтяного газа по ОАО "Татнефть" на уровне 95 процентов, а также даст возможность оптимизировать затраты на топливо и получать прибыль от реализации продуктов газопереработки.

*На правах рекламы*

**АЯК КИЕМЕ РЕМОНТЫ**
17 МАРТТА 9.00 дән 17.00гәчә ТИПОГРАФИЯ БИНАСЫНДА (К.МАРКС УР., 19, 2НЧЕ КАТ) КИРОВ АЯК КИЕМНӘРЕ ФАБРИКАСЫ АЯК КИЕМНӘРЕН РЕМОНТКА КАБУЛ ИТӘ (ТУЛЫ ҺӘМ ӨЛЕШЧӘ).
ТУЛЫ РЕСТАВРАЦИЯ, ФАСОННЫ ҮЗГӘРТҮ.
**ГАРАНТИЯ. СЫЙФАТ.**

12+ "ТНТ-Нурлат" тәкъдим итә

**16 МАРТ**
Музыкаль тапшыру, чуваш телендә.

**18 МАРТ**
"Нурлат хәбәрләре", "Татнефть" хәбәрләре.

**20 МАРТ**
**"Нурлат хәбәрләре".**
**"Сиңа дигән җырым"**, музыкаль тапшыру

Программалар **19 сәгатьтә** башлана. **17, 19, 21 МАРТ** көннәрендә иртәнге **7дә** кабатлап күрсәтелә.

**«KRAUSS»**
**ПЛАСТИК ТӘРӘЗӘЛӘРЕ**
**2015 елның 1 гыйнвареннан 31 декабренәчә 5 тәрәзәгә заказ биргәндә, 6нчысы бүләккә***
**Авыл тәрәзәләре 2000 сум.**
**Откослар, тәрәзә төпләре, москит челтәрләре.**
**Бөтен Татарстан буенча эшлибез.**
**%сыз бүлеп түләү (банклар катнашыннан башка).**
***җентеклерәк 8-9274-000-606, 8-9272-449-000 тел. буенча.**
**«Свет-Окон» ОООсы.**

**ТЕЛӘСӘ НИНДИ КАТЛАУЛЫЛЫКТАГЫ ТАРТТЫРЫЛМА ТҮШӘМНӘР.**
**Профессиональ монтажлау.**
**Түбән бәяләр.8-937-527-43-15.**

**«УЮТ МАСТЕР» компаниясе**
**100дән артык төстәге**
**320 сумнан башлап**
**теләсә нинди катлаулылыктагы тарттырылма түшәмнәр тәкъдим итә.**
**Т. 8-927-246-52-50.**

**АКСУБАЙ ИНКУБАТОРЫ**
**КООБ-500 токымлы бройлерларга заказлар кабул итә.**
**Т.:8-927-671-64-51, 8-843-44-2-78-83.**

**Нурлат муниципаль районы башкарма комитеты төзелеш һәм ТКХ бүлегенең әйдәп баручы белгече вакантлы муниципаль служба вазифасын биләүгә конкурс игълан итә.**

*Муниципаль служба вазифасын биләү өчен түбәндәге квалификацион таләпләр билгеләнгән:*
*һөнәри белем дәрәҗәсенә карата: урта махсус белем, югары һөнәри (төзелеш) белем.*
*Конкурста катнашу өчен түбәндәге документлар кирәк: белем турында документ, паспорт, хезмәт кенәгәсе (күчермәсе), 2 фотография, медучреждение заключениесе.*
**Документлар 20 көн дәвамында Нрулат, Совет ур., 98 адресы буенча 13нче кабинетта кабул ителә. Белешмәләр өчен тел.: 2-06-19.**

ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ СОБРАНИЯ О СОГЛАСОВАНИИ МЕСТОПОЛОЖЕНИЯ ГРАНИЦЫ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА

Кадастровый инженер РГУП БТИ МСАЖКХ РТ Урсаева Эльвира Гакильевна, РТ, 420032, Нурлатский р-он, г. Нурлат, ул.Советская, д.92, кв. 21; ursaeva.elvira@mail.ru 8 (84345) 2-07-89; квалификационный аттестат №16-12-507 выполняет кадастровые работы по образованию земельного участка, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Нурлатский муниципальный район, Бурметьевское сельское поселение, с Курманаево, ул. Животноводская. Заказчиком кадастровых работ является Гарифуллин А. А.

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границы состоится по адресу: Республика Татарстан, Нурлатский муниципальный район, г.Нурлат, ул. Гиматдинова, 52, тел. 8 (84345) 2-07-89 16.03.2015 г. в 9-00.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: г.Нурлат, ул. Гиматдинова, 52; e-mail: nurlat bti@rambler.ru, возражения по проекту межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются с 13.03.2015 г. по 16.04.2015 г.

Для проведения кадастровых работ необходимо произвести процедуру согласования части границы с правообладателями земельного участка с кадастровым номером 16:32:030201:289.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок.

**Нурлат шәһәрендә авыл хуҗалыгы ярминкәсе үткәрелү сәбәпле, 14 мартта 6.00-11.00 аралыгында Гыйматдинов урамындагы юлның 1нче мәктәптән элеваторга кадәр арасы ябылып торачак. Транспорт хәрәкәте чикләнеләчәк.**

Списки избирательных участков местного референдума 26 апреля 2015 года на территории Степноозерского сельского поселения

**Степноозерский избирательный участок № 2348**

Границы: село Степное Озеро. Местонахождение: с. Степное Озеро, муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Степноозерская основная общеобразовательная школа», ул. Школьная, д. 21, тел. 4-63-47.
Количество избирателей - 501

**Илюткинский избирательный участок № 2350**

Границы: деревня Илюткино, поселок Березовка. Местонахождение: д. Илюткино, Филиал муниципального бюджетного общеобразовательного учреждения «Якушкинская средняя общеобразовательная школа», ул. Советская, д. 14, тел. 3-63-14
Количество избирателей – 221.

# АДВОКАТ

Барлык мәсьәләләр буенча юридик консультация.
Дәгъва гаризалары, шикаятьләр әзерләү.
ДТП буенча страховканы алу.
Алиментлар, бүлешү, аерылышу, мирас, хезмәт, пенсия, җир, торак мәсьәләләре.
Җинаять, гражданлык, административ эшләр буенча яклау.
**Т. 8-927-031-21-91.**

